| ГЛАВА АЗАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 ел ,5 ноябрь. № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Шыгай авылы гражданнарының узарара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-РТЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Шыгай авылы, Шоссейная урамы, 18А йорты адресы буенча урнашкан Шыгай авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның узарара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсәләләрне түбәндәгечә расларга: “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2021 елда 250 сум узара салым җыярга һәм күләмендә кертергә, шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тоторга Сез ризамы:

- Шыгай авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Шыгай авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

- Шыгай авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Шыгай авылында Елга урамы буенча авыл эчендәге һәм зиратка илтүче юлларны ремонтлау (таш ташу һәм вак таш җәю);

- Шыгай авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- бензин чапкычлары, ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен отвал һәм запас частьләр сатып алу:

“ӘЙЕ” “ЮК?”

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Азалак авыл җирлеге башкарма комитетына йокләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Азалак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгүлүмәти стентларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Совет Рәисе: И.Г.Габдулгазизов